ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮШАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮШАДЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

# КАРАР

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге Башкарма комитеты

№ 24 25.08.2025ел

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампаларны җыю урыны (урыннары) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашу урыны турында мәгълүмат бирү.

06.10.2003 ел, №131-ФЗ "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" федераль законына, 28.07.2004 ел, № 45-ЗРТ "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы законына, 28.12.2020 ел, № 2314 "Яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә, аларның тиешсез җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган производство һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, 14.03.2024 ел, № 300 "Дәүләт экологик мониторингы (дәүләт әйләнә-тирә мохит мониторингы) турында Нигезләмәне раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегендә кулланылган терекөмешле лампаларны җыю урынын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Югары Юшады авылы, Яңа урам, 2 йорт, Түбән Юшады авылы, Гагарин урамы, 4 йорт,

Каран-Азик авылы, Тынычлык урамы, 22 йорт.

2. Күпфатирлы йортлардагы биналарның хуҗалары, арендага алучылары, кулланучылары булган лампаларны кулланучылар өчен терекөмешле лампаларны җыю урыннары, 2020 елның 28 декабрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан, №2314 карары белән расланган, яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 4 пунктына туры китереп билгеләнә, аларның дөрес җыелмавы, тупланувы, кулланылуы, зарарсызландырылуы, ташылуы һәм урнаштырылуы гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин.

3. Бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән, кулланылган терекөмешле лампаларны җыю урыннары, шул исәптән, күпфатирлы йортлардагы биналарның хуҗалары, арендачылары, кулланучылары булган терекөмешле лампалар кулланучылары өчен дә билгеләнгән, әгәр дә бу күпфатирлы йортларда җыю урыннарын оештыру өчен бипалар булмау сәбәпле, кулланылган терекөмешле лампаларны җыю урыннарын оештыру мөмкин түгел икән.

4. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны җыю урыннары турында кулланучыларны мәгълүмат белән тәэмин итү әйләнә-тирә мохитнең торышы турында федераль дәүләт мәгълүмат системасында, шулай ук Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында (стойкаларда) урнаштыру юлы белән башкарыла.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И. Р. Ханов